

МБДОУ №24 «Росинка»

# Приобщение детей дошкольного возраста к национальной культуре татарского народа через театрализованную деятельность

Воспитатель: Шамеева Ляйсан Рифкатовна

Вся жизнь детей насыщена игрой. Каждый ребенок хочет сыграть свою роль. В душе каждого ребенка таится желание свободной театрализованной игры, в которой он воспроизводит знакомые литературные сюжеты. Научить ребенка играть, брать на себя роль и действовать, вместе с тем помогая ему приобретать жизненный опыт, все это помогает осуществить театр.

Театр – неисчерпаемый источник развития чувств, глубоких переживаний и эмоциональных открытий, способ приобщения к духовному богатству.





Я представляю татарскую разновозрастную логопедическую группу, которую посещают дети в возрасте с 4 до 7 лет с диагнозом общее недоразвитие речи. В нашей группе большое внимание уделяется татарским национальным традициям. Нашу образовательно-воспитательную деятельность с детьми их родителями мы стараемся тесно связать с приобщением детей к культуре татарского народа, его истокам, языку и традиций предков.

В нашей группе также большое внимание уделяется театральной деятельности. Раскрытию творческих способностей способствует богатый уголок по театральной деятельности, где широко используются такие виды кукольных театров, как пальчиковый, театр рукавичек.

Включить детей в театральную деятельность несложно. Дети очень любят наряжаться, изображать каких-то героев.





Театральная деятельность пронизывает все режимные и учебные моменты. Она находит непосредственное отражение в праздниках, досугах, развлечениях, где дети показывают небольшие этюды, сценки из сказок, водят хороводы. Большое и разностороннее влияние театрализованных игр на личность ребенка позволяет использовать их как сильное, но ненавязчивое педагогическое средство, ведь малыш во время игры чувствует себя раскованно, свободно.







**Һади Такташ “ Тәүфыйклы песи”**

Создание спектакля с детьми – очень увлекательное и полезное занятие.

Благодаря театру ребенок познает мир не только умом, но и сердцем и выражает свое собственное отношение к добру и злу; познает радость связанную с преодолением трудностей общения. Исполняемая роль, произносимые реплики ставят малыша перед необходимостью ясно, четко, понятно изъясняться. У ребенка улучшается диалогическая речь, ее грамматический строй.

В условиях роста интереса к культуре татарского народа, особо значимыми становятся вопросы возрождения традиций нравственного воспитания с опорой на национально-культурные, региональные ценности. Устное народное творчество, преподнесенное в форме сценок способствует формированию эмоционального положительного отношения детей к традициям татарского народа. В основе этой работы лежит использование потешек, приговорок, прибауток, колыбельных песен.



Для детей театр - игра, для родителей - праздник, для воспитателей - работа. Эта работа совершается ради того, чтобы театр мог стать игрой, праздником. В своей группе мы привлекаем родителей к активному участию в театрализованных занятиях.

Благодаря совместной деятельности укрепились взаимоотношения между детьми, воспитателями и родителями. . Во время проведения таких мероприятий создаётся неповторимая эмоциональная и духовная атмосфера, поэтому совместно проведённые мероприятия остаются надолго в памяти взрослых и детей.

Таким образом, приобщая детей к истокам татарской народной культуры, мы стараемся сохранить накопленные поколениями богатейший опыт, традиции, ценности, умения и знания.

# “Уйныйбыз да, җырлыйбыз да”

## /фольклор кичәсе/

**Максатлар:** Татар халкының әби-бабайлардан калган гореф-гадәтләрен яңарту һәм алар аша татар теленә мәхәббәт хисләре уяту, балаларны татар халык традицияләрендә тәрбияләү, әдәплеккә, бер-береңә карата игътибарлы булырга, олылырны хөрмәт итәргә өйрәтү.

**Өй күренеше.** Талгын гына татар көе уйный. Әби һәм аның оныкчыгы Алинә кул эше белән кич утыралар.

**Алып баручы:** Әүвәлге заманнарда татар яшьләренең җыелып күңел ача торган урыннары – аулак өйләре булган. Аулак өй – халкыбызның борынгыдан килгән йоласы, яшьләр өчен аралашу, сөйләшү, киңәшләшү, танышу урыны булган. Аулак өйләр һәрчак уен-көлке, җыр-бию белән гөрләп торган. Анда егетләрнең тапкырлыгы, кызларның матурлыгы макталган. Һәм менә шушыларны күз алдында тотып, без сезне үзебезнең аулак өебезгә сәяхәт итәргә чакырабыз.



Әби (оекбаш бәйләп утыра): - Их, бар иде бит ул безнең яшь чаклар. Егетләр урам тутырып җырлап авыл әйләнәләр иде, ә кызлар аулак өйләрдә сер бирмичә генә, егетләрне көтеп утырырлар иде. Ә хәзер искә төшереп утырырга гына калды инде.
Алинә: Әбием, матурым минем сиңа бер йомышым бар иде. Менә эти белән әни дә кунакка киттеләр.Без бүген кызлар белән кич утырып алыйк әле, әбекәем.
Әби: -И-и-и балакаем, бая гына теге егетләр җырлап урам әйләнгәч, яшь чакларымны искә төшереп утыра идем. Ярар, ярар, кич утырсагыз утырыгыз, тик балакаем, бик тәртипле генә була күрегез.

Алинә: Әбекәем, мин сине бик яратам.
Без бик тыныч, бик тәртипле генә, җырлап утырырбыз.
Әби: Ярый, ярый кызым.
Алинә: И-и-и әбекәем, бигрәкләр дә әйбәт инде үзең. Рәхмәт инде, сүз тыңлаган өчен. Мин хәзер кызларны гына чакырып киләм.(кыз китә һәм кызларны чакыра)
Алинә: Кызлар, әйдәгез, керегез.
Кул эшләрен тотып кызлар керә.
Әби: Мин Сәхипҗамал әбиеңнәргә генә кереп чыгыйм әле, йомышым бар иде, карагыз аны, тәртипле генә утырыгыз.(Әби чыгып китә).



В роли бабушки – бабушка Аделя Румина Такиевна

**1-тәрбияче: Кызлар, нигә бик күңелсез утырабыз? Өйдә бездән башка беркем дә юк. Әйдәгез, “Йөзек салыш” уенын уйнап, күңел ачып алыйк. Үзем башлыйм.**

***Йөзек салам , йөзек салам,***
***Йөзек салам үзеңә.***
***Кемдә йөзек сикереп чык.***





**Кызлар тезелешеп утыралар, берәү “Йөзек салучы” була. Ул кулларын тотып утырган кызларның барысына да “йөзек салып” чыга. Йөзекнең кемгә туры килүен берсе дә сизмәскә тиеш. Аннан соң, үзе бер кырыйга китеп: “Кемдә йөзек,сикереп чык”, – ди. Йөзекле кеше сикереп торганда, ике як күршесенең берсе тотып кала алса, йөзекле кешегә җәза бирелә, тота алмасалар, йөзек салуны яңадан башлыйлар. (Җәзага такмаклар )**

**В роли девочки мама Зилиии – Лиана Раисовна**

***•Исәнмесез-саумысыз,***
***Нигә кәжҗә саумыйсыз?***
***Әтәчегез кукәй салган,***
***Нигә чыгып алмыйсыз.***

***•Ике сарык юлга чыккан,***
***Кулларында чемодан.***
***Иреннәрен буяганнар,***
***Ә битләре юмаган.***

***•Көзгегә карыйм әле,***
***Чәчемне тарыйм әле.***
***Әбиләргә бер атнага,***
***Кунакка барыйм әле.***

***•Аягымда кызыл яулык,***
***Башларымда чабата.***
***Җәйнең эссе көннәрендә,***
***Аягым карга бата.***

**(Кызлар көлешәләр).**



**Урамнан гармун тавышы ишетелә.**
**Ишек шакыйлар.**
**Кызлар: Гармун тавышы, гармун тавышы.**
**Кыз:Егетләр килде, егетләр килде.**
**Кызлар тыз-быз килешәләр. Киемнәрен төзәтәләр. Көзге каршында мәж киләләр.**
**2-тәрбияче: Безнең монда җыелганны**
**Әллә кайдан белгәннәр.**
**Егетләр: Кызлар, аулак өйгә кертегез әле?**
**1-тәрбияче: Кертәбезме?**
**Алинә: Юк-юк, әби егетләрне кертергә кушмады.**
**1-2 тәрбияче: Ярый инде керсеннәр.**
**Кызлар барысы бергә: Керсеннәр инде, керсеннәр.**



**“Эх, сез матур кызлар” җыры яңгырый. Егетләр керәләр (кулларында гармун). Зал уртасында кызлар егетләр белән аралашып басалар.**

**1-тәрбияче: Без, без безелдек,**
**Без түгәрәккә тезелдек.**
**Биибез дә уйныйбыз,**
**Бер дә оялып тормыйбыз.**

**Түгәрәктә бию.**



**2-тәрбияче: Ә хәзер, әйдәгез бергәләп, “Кулъяулык” уенын уйнап алыйк. Түгәрәккә басып, көй уйнаганда биеп бер-берсенә кулъяулыкны бирәләр, кемдә кулъяулык кала шуңа җәза бирелә. (Җәзага – тизәйткечләр)**

- ***Тукый-тукый тукыган,***
  ***Тугыз талны чукыган.***
- ***Кара карга кардан бара,***
  ***Канатларын кага-кага.***

*•Әйлән-бәйлән уйныйбыз,*
*Әйләнәбез, биибез.*
*Егылабыз да көләбез,*

*Тагын әйләнә башлыйбыз.*
*Их, күңелле уйныйбыз.*

*•Борын-борын заманда*
*Яшәгән ди бер патша*
*Сарае булган таштан*
*Сөйлимме яңа баштан.*

*Балалар: Сөйлә баштан.*

*Борын-борын заманда*
*Яшәгән ди бер патша*
*Сарае булган таштан*
*Сөйлимме яңа баштан.*
*Балалар: Юк, сөйләмә.*



**1-тәрбияче: Әйдәгез, бер утырып ял итик. (Балалар ике якка бүленеп утыралар).**
**2-тәрбияче: Кызлар, егетләр мәкал әйтешле уйнап алыйк. Мин мәкалне башлыйм, сез дәвам итегез.**
- **Иң татлы тел - ... (туган тел).**
- **Эше барның, ... (ашы бар).**
- **Калган эшкә ... (кар ява).**
- **Кунак булсаң ,... (тыйнак бул).**
- **Эш беткәч, ... (уйнарга ярый).**



•Сөйли белсәң, ... (тыңлый бел!)
•Әткәй шикәр - ... (әнкәй бал).
•Ашыккан - ... (ашка пешкән).
•Егет сүзе ... (бер булыр).
•Бүгенге эшне ... (иртәгә калдырма).

1-тәрбияче: Әйдәгез, табышмаклар да әйтешик.



•Ач дисәң, ачыла,
Яп дисәң, ябыла. (авыз)
•Бертуктаусыз йөри,
Урыныннан кузгалмый. (сәгать)
•Ул булса, көн була
Ул булмаса, төн була. (кояш)
2-тәрбияче: Әйдә, дуслар, бийк әле,
Күңелле чакларда,
Ал чәчәк күк яшик әле,
Бирешмик беркайчан да.
Кызлар, егетләр парлашып бииләр.
(Гармуннар белән бию)

Егетләр: Без китәбез инде, саубулыгыз.
1-тәрбияче: Ашыкмагыз инде, егетләр,
Нигә шулай ашыгасыз.
Уйнап-көлеп алыгыз,
Кичәбездә калыгыз.



2-тәрбияче: Әйдәгез әле, егетләр-кызлар, татар халык уены “Мәликә”не уйнап алыйк. Кемнең беренче күзен бәйлибез, әйдәгез санап чыгарабыз.



Каенда — карга,
Имәндә — чыпчык,
Җирдә — елан,
Һавада — кош,
Бар син дә оч!

Бер бала уртага чыга, аның күзен бәйлиләр. Калган балалар кулга-кул тотышып, түгәрәк ясап әйләнәләр.

(Өченче тапкыр уенга егет чыга, шул вакытта әби килеп керә. Егет әбине кочаклый, әби гаҗәпләнеп кала).



Кызлар:  Әби кайтты, әби кайтты.

Әби (көлә): И-и-и яшь чагымда да, егетләр кочакласа да ояла идем.  Кит әле, кит әле. Кызым, син бит миңа кызлар белән генә кич утырабыз дигән идең!
1-тәрбияче: Син безне ачуланма инде, әбикәй. Үзеңнең дә яшь чакларың булгандыр, сез дә аулак өйләр үткәргәнсездер.
2-тәрбияче: Әйдә, әле әбекәй, яшь чакларыңны искә төшереп, безнең белән биеп тә ал.

Әби белән бергәләп бииләр.

Әби: Булды, балаларым, яшь чакларымны искә төшердегез бүген. Сезнең белән бик күңелле икән.

Әтәч тавышы.

1-тәрбияче: Егетләр, кызлар ишетәсезме? Әнә әтәч кычкыра, таралышырга вакыт җиткән.
2-тәрбияче: Таң атып килгәнен сизми дә калганбыз бит.

